| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

____27.03.2019 ____________ № 280-п

2017-2022 елларга Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районының җирле
әһәмияттәге гомуми файдаланудагы
автомобиль юлларын ремонтлау һәм
норматив хәлгә китерү муниципаль
программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР ЧЫГАРА:

**1.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “2017-2022 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау һәм норматив хәлгә китерү муниципаль программасын раслау турында” 2016 елның 28 октябрендәге 1328-п номерлы карары белән расланган 2017-2022 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау һәм норматив хәлгә китерү буенча муниципаль программага (2018 елның 27 апрелендәге 527-п номерлы карар редакциясендә) (алга таба-Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программа паспорты таблицасында “Еллар һәм чыганаклар буенча бүленгән программаны финанслау күләмнәре” юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре | 2017-2022 елларда Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты хисабына программаны финанслауның гомуми күләме 83 815,035 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2017 елда – 15 978,625 мең сум;<br>2018 елда – 15 136,410 мең сум;<br>2019 елда – 12 600,000 мең сум;<br>2020 елда – 13200,000 мең сум;<br>2021 елда – 13600,000 мең сум;<br>2022 елда – 13300,000 мең сум.<br>Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) Саба муниципаль районы бюджеты турындагы Карары нигезендә төгәллләштереләчәк.<br>Янга калдырылган акчаларны ел саен юл хәрәкәте куркынычсызлыгы чараларына җибәрергә. |

».

**1.2**. нче таблицада Финанслау күләме һәм чыганакларыны (мең сум) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| |
|---|
| Саба муниципаль районы бюджеты,<br>Барлыгы 83 815,035, шул исәптән:<br>2017 ел – 15 978,625;<br>2018 ел – 15 136,410;<br>2019 ел – 12600,000;<br>2020 ел – 13200,000;<br>2021 ел – 13600,000;<br>2022 ел – 13300,000.<br>әлеге Программаның 4 нче таблицасында тәкъдим ителгән финанс чараларын бүлү нигезендә» |

».

**1.3.** 4 нче таблицада:

- 2019 графасында:
  - «3458,220» саннарын «3358,220» саннары белән алыштырырга;
  - «12700,000» саннарын «12600,000» саннары белән алыштырырга .
- 2020 графасында:
  - «2100,123» саннарын «2000,123» саннары белән алыштырырга;
  - «13300,000» саннарын «13200,000» саннары белән алыштырырга.
- 2021 графасында:
  - «2136,858» саннарын «2436,858» саннары белән алыштырырга;
  - «13300,000» саннарын «13600,000» саннары белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны информацион-телекоммуникацион “Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресындагы Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://saby.tatarstan.ru адресындагы Саба муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы И.Б. Таиповка йөкләргә.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Р.Ишниязов